# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлегнә кергән Иске Эсләк авылында урнашкан торак пунктында

« 30» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлегнә кергән Иске Эсләк авылында урнашкан торак пунктында гражданнар җыены **КАРАРЫ**:

1.Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган (I төркем инвалидларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш) 2020 елда 800 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

2.Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Иске Эсләк авылы Үзәк һәм Мәктәп урамнарына вак таш җәю.
- Иске Эсләк авылының Мәктәп урамындагы күперне төзекләндерү.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //agryz.tatarstan.ru игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы И.Н. ГАФАРОВ